**КАРАР №40**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советы утырышы

18 февраль 2022 ел Комыргуҗа авылы

**Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 63 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Комыргуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1993 нче елның 14 маендагы 4979-1 номерлы "Ветеринария турында" гы Федераль законга, 2021 нче елның 11 нче июнендәге 170-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керү сәбәпле, Әтнә районы прокуратурасының 2022 елның 15 февралендәге, 02-08-02/Прдп84-22 номерлы протестын карап һәм тикшереп, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 58 нче номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Комыргуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче бүлекнең 58 нче абзацында «контроль» сүзен төшереп калдырырга;
1.2. 3 нче бүлектәге 3.11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
1.3. 14 нче бүлекнең 14.15 пунктының 1 пунктчасында "терлекчелек продуктлары" сүзләрен "терлек продукциясе" сүзләренә алмаштырырга;
1.4. 15 нче бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә, (1.3 пункт 2023 нче елның 1 мартыннан үз көченә керә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев